МЭР
ГОРОДА БАВЛЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2019 Баулы шәһәре № 28

Баулы шәһәрендә җир участогының рөхсәт ителгән төрен үзгәртү турында

2019 елның 14 майда узган ачык тыңлаулар беркетмәсен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ санлы Федераль законның 28нче статьясы һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә

К А Р А Р И Т ӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Автостоянка участогы адресы буенча урнашкан 16:55:010104:3290 кадастр номерлы 608 кв.м. мәйданлы җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен «автостоянка өчен» дигәннән «сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары)» дигәнгә үзгәртергә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә htpp//bavly.tatar.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында һәм htpp//pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакировка йөкләргә.

Р.Х. Гатиятуллин